**Татарстан Республикасы**
**Арча муниципаль районының**
**Арча шәһәр муниципаль берәмлеге**
**Арча шәһәр Советы**
**422000, Арча шәһәре,Совет мәйданы, 27**
**тел. 3-15-25, 3-16-25**

**Республика Татарстан**
**Муниципальное образование город Арск**
**Арского муниципального района**
**Совет города Арск**
**422000, г. Арск, Площадь Советская , 27**
**тел. 3-15-25, 3-16-25**

**Арча шәһәр Советы**
**КАРАРЫ**

**« 30 » май 2024 ел** **№ 125**

**Арча шәһәр Советының 2022 елның 22 сентябрендәге 81 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә (15.06.2023 №105 үзгәрешләр белән) үзгәрешләр кертү проекты турында**

Арча муниципаль районы Арча шәһәр Советының 2022 елның 22 сентябрендәге 81 номерлы карарына Идел буе транспорт прокуратурасының 2024 елның 02 февралендәге 23/1-12 номерлы таләбе белән бәйле рәвештә, «Россия Федерациясендә тимер юл транспорты турында» 2003 елның 10 гыйнварындагы 17-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясының 3 өлеше нигезендә, шулай ук «Россия Федерациясе прокуратурасы турында» 1992 елның 17 гыйнварындагы 2202-1 номерлы Федераль законның 23 статьясына таянып, Арча шәһәр Советы карар бирде:

1. Арча шәһәре Советының 2022 елның 22 сентябрендәге 81 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә (15.06.2023 №105 үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 бүлектә 9 статьяның 2 өлеше 3 пунктында «һәм тимер юлларын 20 м» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 59 статьяның 4 өлеше 15 пункында «һәм тимер юл транспорты контакт челтәренең терәкләрен» сүзләрен төшереп калдырырга;

3) 15 бүлектә 60 статьяның 1 өлешендә «тимер юл транспорты контакт челтәренең терәге» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Арча шәһәр Советының 2022 елның 22 сентябрендәге 81 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә (15.06.2023 №105 үзгәрешләр белән) үзгәрешләр кертү проекты буенча гавами тыңлауларны 2024 елның 21 июнендә 17.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы, Арча шәһәре, Совет мәйданы, 27 йорт адресы буенча билгеләргә.

3. Гавами тыңлауларда катнашу өчен тәкъдимнәр, карар проектына искәрмәләр һәм гаризалар әлеге карар Арча муниципаль районының рәсми сайтында яисә гражданнар күпләп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларында урнаштырылган көннән алып 2024 елның 21 июненә кадәр эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән алып 17.00 сәгатькә кадәр язма рәвештә Арча шәһәр Советына ТР, Арча шәһәре, Совет мәйданы, 27 йорт адресы буенча кертелә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

«Арча шәһәре» муниципаль
берәмлеге башлыгы,
Арча шәһәр Советы рәисе

И.Г. Нуриев